Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
“Колбай Мораса урта гомуми белем мәктәбе”

**КИЛЕШЕНГӘН**
Директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары:
_________Ибрагимова Г.Н.
Протокол № 8
24 март 2024 ел.

**РАСЛЫЙМ**
Мәктәп директоры:
_________Валеев.М.И
Приказ №12
«25» март 2024 ел.

**5-11 нче сыйныф укучылары өчен**
**“Туган телдә яшь журналист мәктәбе”**
**проектының**
**эш программасы**

9 нчы сыйныф укучысы Ахметзянова А.А.,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Галиуллина Р.Г.

**2024 нче ел**

## Аңлатма язуы

**“Туган телдә яшь журналист мәктәбе”** проекты яшьтәшләрем арасында югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтне үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү юнәлешендә эш алып бара. Уйлаган фикереңне матур һәм дөрес итеп башкаларга җиткерә белү- милли культураның бер өлеше. Укучыларның язма һәм телдән сөйләмен үстерү, аларда газета, радио, телевидение теленә карата дөрес мөнәсәбәт формалаштыру балаларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт-мөмкинлекләренә уңай тәэсир итәрлек итеп оештырылырга тиеш. Әлеге “Туган телдә яшь журналист мәктәбе” проекты программасы шушыларны истә тотып төзелде. Мондый эшчәнлек укучыларга сөйләм культурасын, иҗади мөмкинлекләрен үстерергә, ана телебезгә кызыксыну уятырга ярдәм итә; эстетик тәрбия бирү, аларның үз фикерләвен киңәйтү, аралашу культурасын үстерү, коллективта иҗади эшли белү сәләтен үстерүне күздә тота.

Бөтен кеше дә язучы, журналист була алмый. Әмма язма рәвештә үз фикерен логик эзлеклелектә әйтә белү табибка, укытучыга кирәк булган кебек, төзүчегә, эшчегә һәм тегүчегә дә бер үк дәрәҗәдә кирәк. Хәзер кешенең рухи дөньясы, фикерли белүе беренче планга чыга бара. Шуңа күрә үз фикереңне эзлекле, дәлилләп һәм сурәтләп әйтә белү, фикереңне дәлилләп бәхәстә катнаша белү - бик кирәкле сыйфат. Әлеге проектта катнашу укучыларга үзләрендә бу сыйфатны үстерергә мөмкинлек бирә. Иң мөһиме шул:төрле иҗади эшләр белән шөгыльләнгән укучыларның дөньяга үз карашлары, мөстәкыйль фикерләүләре булдырыла.

Яшь хәбәрчеләр белән эшләү оештыручыдан да иҗади активлык сорый. Мондый эшчәнлек укучыларга сөйләм культурасын, иҗади мөмкинлекләрен үстерергә,татар матбугатына карата кызыксыну уятырга ярдәм итә. Әлеге программа эше вебинар-элемтә дип аталса да, ул структур яктан традицион формадагы дәресләргә охшаган: оештыру, актуальләштерү, яңа материалны аңлату, ныгыту, йомгаклау. Дәресләрдә ныгытуга, ягъни гамәли эшкә, күнекмәләр бирүгә вакытның күпчелек өлеше сарыф ителә, кайбер вебинар-элемтә тулысы белән практик эшкә багышлана.

Программа атнасына 2 сәгать исәбеннән төзелде. Барлыгы сәгатьләр саны – 16. Түгәрәк атнаның чәршәмбе һәм җомга көннәрендә 13.30-14.30 сәгатьләрдә үткәрелә. Бу проектта 5-11 нче сыйныф укучылары, җәмәгатьчелек катнаша.

### Проект түбәндәге педагогик принципларга таяна:

**Программаның максаты:**
журналист һөнәренең серләренә төшендерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләре белән таныштыру; эзләнүчән шәхес формалаштыру.

**Бурычлары:**

- вакытлы матбугат жанрлары, аның төрләре белән таныштыру;

- газета чыгаруда иң кирәкле булган: тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү серләренә төшендерү;
- газета теле үзенчәлекләрен өйрәтү;
- газета-журналлар басу технологиясе турында мәгълүмат бирү;
- яшьтәшләремнең газета жанрларына караган материалларны дөрес итеп язарга өйрәнүләренә ирешү;
- балаларның фикерләү сәләтләрен үстерү, иҗат активлыкларын киңәйтү;
- эстетик зәвык тәрбияләү;
-туры элемтәдә. “Сферум” интернет челтәре аша вебинарларда катнашу.

**Көтелгән нәтиҗә:**
Журналист һөнәренең серләрен үзләштерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләрен аңлау һәм иҗат эшенә тартылу.

**Эш методлары һәм формалары:**
- лекция
- практикум
- вебинар
- эшлекле уен
- иҗат ителгән әсәрләрне тәкъдим итү
- проект эше яклау
- очрашу-әңгәмә
- экскурсия.

## Календарь-тематик планлаштыру

| № | Шөгыльләрнең эчтәлеге | Сәгатьләр саны | Дата |
|---|---|---|---|
| 1 | Оештыру эшләре. (Укучыларны проект эшенә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү, мәктәп сайты белән танышу).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 03.04.2024 |
| 2 | Массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмә. Нәрсә ул максатчан аудитория? (Г.Кариев исемендәге музей директоры Валиуллина Л.К. белән очрашу).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 05.04.2024 |
| 3 | Газета жанрлары. Рубрикалар. Газетадагы “полосалар”. Материалны компьютерда җыя белү .Газета ничек ясала? Татар телендә чыгучы газета-журналлар. Син балалар матбугатын беләсеңме?Газеталарга күзәтүләр. | 1 | 10.04.2024 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | | |
| 4 | Нурлат ТВ. Хәбәрчегә хас сыйфатлар. Аралашу-үзе сәнгать. .”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 12.04.2024 |
| 5 | Хәбәр язарга өйрәнәбез. Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу. Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт. Мәкалә язу серләре. Мәкаләгә исем кую .Мәкаләне коррекцияләү .(Кариев исемендәге музей директоры Валиуллина Л.К.) ).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 17.04.2024 |
| 6 | 9 нчы сыйныф укучысы Ахметзянова Айгөлнең мастер –классы.Темалар аяк астында Интервью – иҗади гапләшү. ).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 19.04.2024 |
| 7 | “Дуслык” газетасы һәм Нурлат телевиденисенә экскурсия. | 1 | 24.04.2024 |
| 8 | Газета -журналлардагы фотосурәтләр. Мәгънәләре. Ничек фотосурәт төшерергә? ).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 26.04.2024 |
| 9 | Яңа технологияләр. Электрон газета. Конкурсларда катнашу Татарстанның балалар вакытлы матбугатына мәкаләләр язу һәм җибәрү. Г.Тукай туган көненә панорама - стенгазета чыгару (Ахметзянова Айгөл).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 30.04.2024 |
| 10 | Репортаж. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу. Редколлегия утырышы, материалларны урнаштыру. Корреспонденция- җәмәгатьчелек иътибарын проблемага юнәлтә (Валиуллина Л.К.). ”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 03.05.2024 |
| | | | |
| 11 | Реклама, белдерү. Сатирик жанрлар. Котлау язу. Татарстан балалар вакытлы матбугатына материаллар язу (Галиуллина Р.Г.).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 08.05.2024 |
| 12 | Телефон белешмәсе – журналистның ярдәмчесе Телевидение җиһаны Телевидение журналистының кыяфәте, этикеты (Мөбәрәкшина Л.М.).”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | 1 | 10.05.2024 |
| | | | |
| 13 | Журналист тикшерүе “Яңалыклар” чыгарылышы. Редколлегия утырышы. Мәктәптә “Каурый каләм” | 1 | 15.05.2024 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | газетасын чыгару.”Сферум” интернет челтәрендә вебинар-элемтә. | | |
| 14 | Универсаль журналист. Профессиональ журналист белән очрашу. Музейга кунакка бару. | 1 | 17.05.2024 |
| 15 | Журналист буларак ТВ да үз-үзеңне тоту, киенү, сөйләм. | 1 | 22.05.2024 |
| 16 | Газетаны чыгарылышка әзерләү.<br>Еллык нәтиҗәләр. Иң яхшы яшь хәбәрчеләрне бүләкләү.<br>Зачет бирү. Курс таныклыгы тапшыру. | 1 | 24.05.2024 |